Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

№ 3 10 ноябрь 2025 ел

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Азат торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Бердәм гавами хакимияттә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР бирәм::

1. 2025 елның 21 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Азат авылында үз-үзеңә салым салу акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышы билгеләнсен.2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Азат авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Азат торак пункты чикләрендә юл полотносын урнаштыру, шул исәптән: туфрак күтәрү, сатып алып вак таш сибү, тигезләү (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү), торак пункт эчендәге юлларны кышкы карап тоту, шул исәптән: урамнарны кардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу).

**2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

- су белән тәэмин итү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Азат торак пунктында суүткәргеч челтәрен ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3 . Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubaevo.tatar.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы

Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы А. В. Макаров